учащимся более адекватно участвовать в процесс межкультурной коммуникации.


**Литература**

1. Ермолович Д.И. Англо-русский словарь персоналий. – М.: Русский язык, 1999. – 333 с.
2. Матюшенков В.С. Англо – русский словарь особенностей английского языка в Северной Америке, Великобритании и Австралии – М.: Флинта, Наука, 2012. – 517 с.
3. Методические рекомендации по формированию культуры работы со словарями школьников и педагогов общеобразовательных учреждений в целях реализации положений ФГОС», ФГБУН Институт русского языка им. В В. Виноградова РАН, письмо Минобрнауки РФ от 6 мая 2013 г. No 08-535) – URL: uchitel-slovesnik.ru/data/uploads/den-slovara-2017/koncepcia.docx (дата об-ращения 25.09.2017)
4. Ощепкова В.В., Шустилова И.И. Краткий англо- русский лингвострановедческий словарь – М.: Флинта, 2005. – 176 с.
5. Томахин Г.Д. Лингвострановедческий словарь. Соединенное Королевство Великобритании и Северной Ирландии – М.: АСТ ПРЕСС КНИГА, 2003. – 709 с.
6. Longman Dictionary of English Language & Culture. – London: Longman, 2010. – 1528 с.



**УДК 811.512.145**



**Х.Х. Сулайманова**

*Многопрофильная полилингвальная гимназия №180, г. Казань, Россия*


# СИСТЕМА КОНТРОЛЯ – ОСНОВНОЕ НАПРАВЛЕНИЕ ОЦЕНИВАНИЯ ЗНАНИЙ УЧАЩИХСЯ


***Аннотация***. *За последние годы значительно активизировалась работа по совершенствованию методов и средств контроля в условиях школьного обучения. В данной статье рассматриваются проблемы совершенствования системы контроля знаний на основе интерактивных тестов, которые позволяют выявить уровень знаний и умений учащихся по татарскому языку.*



***Ключевые слова***: *традиционные формы, современное средство контроля, тестовый контроль, объективность, педагогический мониторинг.*



**H.H. Sulaimanova**

*Multidisciplinary polylingual gymnasium No. 180, Kazan, Russia*


# CONTROL SYSTEM – THE BASIC DIRECTION OF ASSESSMENT OF KNOWLEDGE


***Abstract***. *The efforts to improve the methods and means of control in school have been intensified over the last several years. This article discusses the problems of improving monitoring systems, knowledge-based interactive tests and of monitoring that can help understand the level of the Tatar language learners.*



***Key words***: *traditional and modern means of control, test control, fairness, pedagogical monitoring.*


Соңгы вакытта мәгариф өлкәсендә белем бирүнең өстенлекләре нык үзгәрде. Элегрәк белемнәр югары бәяләнсә, хәзер исә беренче урынга гомуми белем күнекмәләре чыкты: ягъни белемне үзләштерә һәм нәтиҗәле куллана белү күнекмәләре булдыру алгы планга куела, шуңа күрә белемнәрне яңарту һәм тулыландыру юлларына ия булу сорала. Укучының киләчәге үзләштергән белемнәрен ничек куллана белүенә һәм мәктәптән соң никадәр мөстәкыйль эш итә алуына бәйле. Бу исә белемне үзләштерү һәм куллана белү дәрәҗәсе генә түгел, ә коммуникатив күнекмәләр, үзконтроль һәм иҗади сәләтенең үсеше дә.

Хәзерге чорда мәгариф системасын яңартуның төп максаты-укытуның сыйфатын күтәрү. Белемнең яңа сыйфаты ул белемнәрнең билгеле бер җыелмасын үзләштерүгә генә түгел, ә бәлки шәхес үсешенә, аның танып-белү, көндәшлек итә алу сәләте, эшлеклелеге сыйфатлары үсешенә дә юнәлтелгән булуы.

Укучыларның белем сыйфатын бәяләүнең төп юнәлеше булып белемнәрне тикшерү системасы

тора. Педагогик эшчәнлектә дә төп бурычларның берсе белем сыйфатын тикшерү, аның эчтәлеге, үткәрү формалары, методлары өстендә эшләү, тикшерү нәтиҗәләрен анализлаудан гыйбарәт.

Тикшерү – киң мәгънәле төшенчә. Ул уку-укыту процессында даими урын алырга тиешле гамәл. Аның ярдәмендә укучыларның белемнәре никадәр тулылана баруы, аңлы рәвештә үзләштерелүе, системалылыгы, ныклыгы, тотрыклылыгы, укучы тарафыннан иркен үзләштерелә, практикада файдаланыла алуы тикшерелә.

Укучыларның белемнәрендәге кимчелекләрне, җитешсезлекләр һәм ялгышларны ачып, аларны бетерү чараларын билгеләргә мөмкин. Шул рәвешчә, белемнәрне тикшерү даими рәвештә аларны камилләштерү максатына хезмәт итә. Белемнәрне тикшерүне дөрес куйганда, ул укучыларда белемнәренең сыйфаты өчен җаваплылык тойгысын үстерә, аларны үзләренә таләпчән булырга, ялгышларны кабатламау чараларын күрергә өйрәтә. Шунлыктан укучыларның белем дәрәҗәләренә булган таләпләр турында укытучы гына түгел, ә укучы үзе дә белергә тиеш. Шул таләпләр турында хәбәрдәр булу гына - җитешсезлекләрне бетерү эшенең беренче адымы [5].

Педагогик процесста тикшерүнең бик күп төрләре кулланыла: агымдагы күзәтү юлы белән укучыларның белемнәрен һәм эшләрен исәпкә алу, белемнәрне тикшерү максаты белән укучылардан сорау, язма һәм практик биремнәр, язма контроль эшләр, диктантлар, изложениеләр... Хәзерге вакытта татар теле дәресләрендә тикшерүнең традицион булмаган яңа формаларына һәм алымнарына зур игътибар бирелә. Тәҗрибә күрсәткәнчә, бүген тикшерү чаралары арасында компьютер тестларын куллану инновацион алымнарның берсе булып санала, чөнки алар ярдәмендә белем алучыларның ирешелгән уңышлары турында дөрес һәм төгәл мәгълүмат алу мөмкинлеге булдырыла [2]. Фәнни хезмәтләрдә әйтелгәнчә, тест – билгеле бер биремнәр системасын, стандартлаштырылган үткәрү процедурасын, алдан уйланылган нәтиҗәләрне эшкәртү һәм анализлау технологиясен үз эченә алган һәм шәхеснең сыйфатларын бәяләүгә юнәлтелгән корал ул [3]. Тестлар укучыларның белем һәм күнекмәләрен тикшерүдә объектив һәм уңайлы ысулларның берсе булып тора, укучыларның фәнне өйрәнүдәге уңышларын сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да бәяләргә мөмкинлек бирәләр. Башка тикшерү чараларыннан аермалы буларак, тестлар куллануның өстенлекле яклары шактый:

- тикшерү үткәрү процедурасының техник яктан күпкә җиңел булуы;
- барлык укучылар өчен дә биремнәрнең бер типта булуы;
- нәтиҗәләрне бәяләүдә объективлык;
- тикшерү үткәрүче укытучының субъектив фикере исәпкә алынмавы;
- фән буенча укыту материалының тулысынча кулланылуы;
- укучыларның белем дәрәҗәләрен чагыштырып анализлау мөмкинлеге;
- нәтиҗәләрне тиз арада белә алу [2] .

Яңа педагогик технологияләрнең бер өлеше булган тестларны эшләү барышында укучының белеме системалаша. Мондый төр биремнәр кыска һәм сайлап алу җаваплары таләп иткәнлектән, укучылар үзләштергән белемнәрен тиз арада куллана ала. Шул ук вакытта укучының белемнәрендә һәм җавабының сыйфатында нинди кимчелекләр барлыгын, җитешсезлекләрне бетерү, үзенең белемнәрен яхшырту өчен ни эшләргә кирәклеген укучыга, класска тиз арада һәм аңлаешлы итеп әйтеп бирүнең гаять зур әһәмияте бар. Белем тикшерүдә компьютер чараларын куллану укытуның нәтиҗәлелеген бермә-бер арттыруга китерә.

Тестларга куелган төп таләпләр: кыскалык, төгәллек һәм сорауның дөрес төзелгән булуы. Тест сорауларының төгәл булмавы күп вакыт укучыларда авырлык тудыра. Тестларны әзерләгәндә, ике өлештән төзү отышлы: теориягә караган тест сораулары һәм гамәли тест сораулары. Сораулар, гадәттә, “җиңелдән-авырга” принцибы буенча төзелә. Тестларның электрон вариантта булуы системалы эш алып барырга уңайлыклар тудыра, чөнки, вакытлар үткән саен, тестларны тулыландырырга, аерым сорауларны үзгәртергә, ә кайберләрен алыштырырга мөмкинлек була.

Тест технологиясеннән файдаланганда, укучы белем бирү процессында үзәк урынны ала. Бу очракта укытучы төп мәгълүмат чыганагы булудан туктый, ә укучыларның эшчәнлеген оештыручы һәм аның белән идарә итүче ролендә кала. Укучылар тестны яхшы башкарсын өчен, аларда тел компетенциясе формалашкан булырга тиеш. Моның өчен максатны дөрес итеп куярга, укучыга укыр өчен шартлар тудырырга, ягъни авторитар, классик технологиядән шәхескә юнәлдерелгән технологиягә күчү килеп туа. Бигрәк тә, хәзерге вакытта укучыларның белемен объектив рәвештә тикшерү өчен тестлар файдалану кирәк, чөнки Бердәм дәүләт имтиханнары материалларының бер өлеше тестларга нигезләнгән. Укучылар имтиханнарны уңышлы тапшырсын өчен, башлангыч сыйныфлардан ук аларны төрле типтагы тестлар белән эшләргә күнектерү мөһим. Шунлыктан, дәрестә үзләштергән материалны тикшерү өчен даими рәвештә тестлардан файдалану бик отышлы.

Укучы алдан белемне үзләштерүенең тест формасында тикшерелəсен белə, шунлыктан куелган максатка ирешү өчен тырыша. Тест биремнəренең төрле формалары белəн эшлəү мөмкинлеклəре бар: ачык һəм ябык тестлар; тəкъдим ителгəн вариантлардан берничə дөрес җавапны сайлап алу тестлары; тəңгəллек булдыру яки җавапларны эзлекле рəвештə урнаштыру биремнəре һ.б. [2]. Һəр очракта тикшерү эшен төрлечə оештыру һəм, татар теле үзенчəлеклəрен истə тотып, тестларның теге яки бу төрен куллану мөмкинлеге бар. Мəсəлəн, тематик тестлар, зачет, башка белемнəрне тикшерү тестлары булырга мөмкин.

Һəр дəресне диярлек аерым темалар буенча əзерлəнгəн кыска тестлар белəн башлап җибəрəргə мөмкин, шулай ук фронталь сорау алу яки карточкалар ярдəме белəн мөстəкыйль эш үткəреп тə була. Группалар белəн эшлəү һəр укучыга компьютер җитмəүдəн дə котылырга ярдəм итə, шулай ук классның 70 % тан артыгы дəрес саен билге дə ала. Укучыларга исə үткəн дəрес материалын гына түгел, ə даими рəвештə алда өйрəнелгəн темаларны да кабатларга туры килə.

Гамəлдəге тикшерү алымнары белəн беррəттəн, инновацион технологиялəрдəн файдалануның мөһимлеге заман талəплəреннəн чыгып билгелəнə. Укучыларның белемнəрен тикшерүгə юнəлтелгəн яңа эш төрлəре традицион формаларны тулыландырырга, стандартлаштырырга, белем бирү өлкəсендə эзлеклелек һəм системалылык булдырырга мөмкинлек бирə.

Нəтиҗə ясап, шуны əйтергə кирəк: яшь буынга сыйфатлы белем бирү, аны тормышка əзерлəү – бүгенге дəүлəт, хөкүмəт, мəгариф системасы, бөтен җəмгыять алдында торган иң мөһим бурычларның берсе.

### Əдəбият


1. Веспалько В.П. Педагогик технологиялəр кушылмасы. – М.:Педагогика, 1989. – 530 б.
2. Габдрахманова Л., Фəтхуллова К.С. Педагогик эшне тикшерүдə компьютер чараларын куллану / Мəгариф. – 2008. – №12. – Б. 49-52.
3. Галеев И.Х., Храмов В.Г., Колосов О. В. Компьютерный контроль знаний: учебное пособие. – Казань: КГТУ, 2005. – 126 с.
4. Педагогика, психология һəм укыту методикасының актуаль мəсьəлəлəре. – 2002. – № XVI. – 94 б.
5. Хуҗиəхмəтов Ə.Н. Педагогик технологиялəр. Икенче китап. – Казан: Мəгариф, 2008. – 366 б.



**УДК 378.016:811**



**О.В. Сунгурова**

*Вятский государственный университет, г. Киров, Россия*


## ИСПОЛЬЗОВАНИЕ ИНТЕРНЕТ-ТЕХНОЛОГИЙ ДЛЯ ОПТИМИЗАЦИИ САМОСТОЯТЕЛЬНОЙ РАБОТЫ СТУДЕНТОВ ЯЗЫКОВЫХ ФАКУЛЬТЕТОВ


***Аннотация***. *В статье представлены пути повышения качества самостоятельной работы студентов посредством Интернет-технологий, особое значение уделено их мотивационному потенциалу и роли в формировании языковой компетенции.*



***Ключевые слова***: *самостоятельная работа студентов, Интернет-технологии, мотивация, самообучение, языковая компетенция.*



**O.V. Sungurova**

*Vyatka State University, Kirov, Russia*


## USING INTERNET TECHNOLOGIES FOR THE OPTIMIZATION OF THE STUDENTS' INDEPENDENT WORK AT THE FACULTY OF LINGUISTICS


***Abstract***. *The article reveals the ways to increase efficiency of the students' independent work at the Faculty of Linguistics. The significance of this type of work for the language competence has been analysed. Special attention is paid to the motivation aspect of Internet technologies.*



***Key words***: *students' independent work, Internet technologies, motivation, self-study, language competence.*